СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

21.12.2021 Әгерҗе ш. № 14-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында нигезләмә;

- Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен төп күрсәткечләр, аның максатчан күрсәткечләре һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 сентябрендәге 11-2 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының шәһәр төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә буенча «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә (Башаров Р.Р.).

Совет рәисе
муниципаль берәмлек башлыгы Ә.Р. Вәлиев